# Г. Тукай иҗатында экология темасы



**Экология** (грек сүзе) эйкое – йорт, тереклек ияләре һәм үсемлекләрнең яшәү урыны; логос – закон, канун дигәнне аңлата.

Кояш, су, ком, таш, хайван һәм үсемлекләр – барысы бергә **табигать дип атала.**

Кеше табигатьтән башка яши алмый. Табигатькә чыгып, без ял итәбез, кошлар җырын тыңлыйбыз, хуш исле үләннәр, чәчәкләр иснибез, күңелләребезне сафландырабыз. Мәрхәмәтлелек тамыры табигатьтән башлана. Ә мәрхәмәтлелек ул – мәхәббәт, ярату. Мәхәббәт – җәнлекләрне, кошларны, бар табигатьне ярату, саклау. Табигатьнең матурлыгына хозурлану гына аз, аны саклый, аңлый белергә дә кирәк.

Экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең әһәмияте зур. Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде. Нәфис сүз, сәнгать чаралары ярдәмендә кешедә югалып бара торган иң изге әхлакый-рухи кыйммәтләрне торгызу, Җир-анага игелек, хөрмәт хисләрен уяту, кешелекнең экологик һәлакәт каршында торуында искәртергә кирәк иде.

**Фәнни эшемне** “Тукай иҗатында экология темасы” дип атадым.


***Теманың актуальлелеге:*** халкыбызның улы, бөек шагыйре
Г. Тукайның иҗаты турында күп язылды, күп укылды. Әдәбият белгечләребез һаман да аның биографиясенең, иҗатының ачыкланып бетмәгән кайбер фактларын тикшерәләр, барлыйлар.

Эш барышында мин дә үземә шундый ***максатлар*** куйдым:

1. Шагыйребезнең тормыш юлы, иҗаты белән танышу;
2. Аның турындагы язмаларны эзләү, аларны тирәнтен өйрәнү;
3. “Экология” термины белән танышу.
4. Бөек шагыйребезнең экология һәм аның проблемаларына багышлап язылган шигырьләренә күзәтү ясау, экология мәсьәләсенең куелышын ачыклау.

Табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Г. Тукай күп кенә шигырьләрендә җәнлекләрне, кошларны, бөҗәкләрне яратырга, аларга мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау – милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, рухи һәм тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки туган тел, әдәби һәм тарихи мирас газиз җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген Тукаебыз үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.
(“Туган авыл” Г.Тукай)




24

Саргаядыр көз көнендә һәр агач яфраклары;
Юк яшеллекләр хәзер, урман вә сахра сап-сары.

Саргая таллар, усаклар, алмагачлар һәм каен;
Хәстә төсле, арта сары төс аларда көн саен.

Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе бар:
Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.

(Г. Тукай “Чыршы”)





Күрәмсез, дустларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.
Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.
(Г. Тукай «Көз»)





Белмисеңме син: читен мәхбүслек ул,
Булса да алтын, һаман да читлек ул.

(“Сандугач белән Фатыйма”)





# “Кошларга”









№ 3
2006 ел

Габдулла ТУКАЙ

## Гали белән Кәҗә

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.
Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

## Гали и Коза

С Козою дружит наш Гали который год.
Он вместе с ней гулять идет на огород.
Свою Козу там угощает он травой,
Ну а Коза трясет довольно бородой.

Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА

# “Бичара куян”



- - И Куян, куркак  Куян, йомшак Куян, Моңланасың нинди хәсрәт, кайгыдан???

Фани дөнья! Нинди эшләр эшлисең син шак та кат!
Шундый шат уйнап йөргән песи инде вафат!

«Мияубикә”



# “Шүрәле ” поэмасы



- Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл — «Кырлай» диләр;
- Җырлаганда көй өчен, «тавыклары җырлай», диләр.


Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем;
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.
Ул авылның, һич онытмыйм, һәрьягы урман иде,
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
Зурмы, дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халкының эчкән суы бик кечкенә — инеш кенә.
Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава;
Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява.
Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.
Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.
Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән


# “Су анасы”



Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман кайный Казан;
Имгәтеп ташла савын, сау эшчеләр сайлый Казан.

(“Казан”)







# Йомгаклау

- Бөек шагыйребез “Экология” фәнен өйрәнмәсә дә, Җир һәм анда яшәүчеләрнең тормышлары өчен борчылган. Ул табигатьнең кешегә яшәү өчен матди мөмкинлекләр дә, иҗат өчен илһам да бирүен дөрес аңлаган. Экологиянең чикләре бик киң. Тукай бу мәсьәләгә дә төрле яктан якын килә. Әйтелгән фикерләр шагыйрьнең бик күп әсәрләрендә чагылыш тапканын күрдек. Гомумиләштереп әйткәндә, Г. Тукай иҗатында туган як образы зур урын алып тора. Туган ягына булган мәхәббәтен иҗат җимешләре аша укучыларына җиткерә шагыйрь.

  Һәм шушы әсәрләре белән ул кешеләргә: “Табигатьне саклагыз!” – дип әйтә кебек.

- Бүгенге көндә кешеләр табигатьне сакламыйлар. Елгалар пычратыла, хайваннар үлә, күп кенә үләннәр, чәчәкләр, агачлар юкка чыга. Габдулла Тукай табигатьне сакларга тырышкан. Безне дә шуңа чакыра!

# *Игътибарыгыз өчен рәхмәт!*

